



# Татар телен өйрәнәбез.



# ***<u>АЙ ҖАНЫЙ, ВАЙ ҖАНЫЙ</u>***

*Татар халык җыры*

**Уфа,Казан**
**Юлларының**
**Баганалары чыршы.**
**Башларына**



## *КАЗАН КИЧЛӘРЕ*



**Кил әле, Иделнең җиләс җиле,**
**Юлларга чәчәкләр сип әле.**
**Ак булып, саф булып истә калсын**
**Казанның кадерле кичләре.**

**Туган ил чакырган зур юлларга**
**Китәрбез таңнарда без моннан.**
**Озатып калырсың безне,**
**Казан, Баласын очырган кош сыман.**

**Яшәрбез туган җир туфрагында,**
**Кырларда, Иделдә-диңгездә.**
**Исән-сау булсыннар балалар, дип,**
**Хәерле юл телә, Ил, безгә.**



**1.Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.**
**Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!**

**2.Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын:**
**Сөйләшәләр үзара: “Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!”**

**3.Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;**
**Ансы да сөйли тагын: “Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!”**



**1.Сез дә безгә кушылыгыз—**
**Без шатлык таратабыз,**
**Тирә-якны яңгыратып**
**Җырларга яратабыз.**
**Әйлән-бәйлән,2**
**Безнең белән,2 әйлән!**
**Җыр ул – канат, җыр ул – бәйрәм!**
**2.Без биибез тыпыр/2/,**
**Без биибез тып да тып.**
**Бер башласак, бик тиз генә**
**Булмый безне туктатып.**
**3. Йәгез, сез дә кушылыгыз,**
**Утырмагыз, торыгыз!**
**Җырлый/2/ биик әле,**
**Сез кул чабып торыгыз.**



**<u>Әссәламегаләйкем</u>**

**1.Таң ата да кояш чыга,**
**Кояшны сәламли көн.**
**Саумы, Кояш, сүнмәс учак!**
**Әссәламега-ләйкем!**

**2.Тел ачкычы, иман биргән**
**Сөекле туган телем!**
**Үз телемдә сәлам юллыйм,**
**Әссәламега-ләйкем!**

**3. Ачыйк бәхет ишекләрен,**
**Бәхетле булсын һәркем.**
**Саумы кояш сүнмәс учак**
**Әссәламегаләйкем.**

# <u>Туган тел</u>
# Габдулла Тукай



**И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!**
**Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.**
**Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,**
**Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.**
**И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,**
**Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.**
**И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:**
**Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам!**



**<u>Бишек җыруы</u>**

**Габдулла Тукай**

**Әлли-бәлли итәр бу,**
**Мәдрәсәгә китәр бу;**
**Тыршып сабак укыгач,**
**Галим булып җитәр бу.**
**Йокла, угълым, йом күзен,**
**Йом, йом күзең, йолдызым;**
**Кичтән йокың кала да,**
**Егълап үтә көндезең.**
**Әлли-бәлли көйләрем,**
**Хикәятләр сөйләрем;**
**Сина теләк теләрем,**
**Бәхетле бул, диярем.**
**Гыйззәтем син, кадрем син,**
**Минем йөрәк бәгърем син;**
**Куанычым, шатлыгым**
**Тик син минем, синсең, син!**

***Гыйззәтем — кыйммәтлем.***

# <u>Ənisə.</u>

*татар халык җыры*



**Тыпыр-тыпыр биергə**
**Тимер идəннəр кирəк.**
**Тимер идəннəр өстенə**
**Хəтфə паласлар кирəк.**
**Хəтфə паласлар өстенə**
**Имəн өстəлләр кирəк.**
**Имəн өстəлләр өстенə**
**Көмеш табаклар кирəк.**
**Көмеш табаклар эченə**
**Хөрмə-җимешлəр кирəк.**
**Хөрмə-җимешлəр ашарга**
**Алтын кашыклар кирəк.**
**Алтын кашыклар тотарга**
**Кара кашлы кыз кирəк.**
**Кара кашлы кыз каршына**
**Батыр егетлəр кирəк.**



# ***<u>Көз</u>***
# ***Габдулла Тукай***

*Күрәмсез, дустларым, көз килде тышта;*
*Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.*
*Китә башлады бездән инде кошлар;*
*Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.*
*Мисале зәгъфыран саргайды урман,*
*Игенчеләр игеннәрне дә урган.*
*Такыр калды татар башы кеби кыр;*
*Азык эзли — оча тургай да пыр-пыр.*
*Чыгып баш калкыта сахрада уҗым,*
*Яшел хәтфә шикелле итә җем-җем.*



# <u>АЙ БЫЛБЫЛЫМ</u>


*Татар халык җыры*

*Ай былбылым, вай былбылым,*
*Агыйделнең камышы;*
*Таң алдыннан чут-чут килә*
*Сандугачлар тавышы.*

*Ай былбылым, вай былбылым,*
*Агыйделдә таң ата;*
*Таңнар ата, өзелә үзәк,*
*Җырлата да елата.*

*Ай былбылым, вай былбылым.*
*Кунып сайрый талларга;*
*Сннең хакта серләремне*
*Сөйлим сандугачларга.*

# Туган авыл
## Габдулла Тукай




*Тау башына салынгандыр безнең авыл,*
*Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;*
*Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,*
*Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.*
*Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,*
*Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;*
*Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәтне,*
*Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.*
*Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,*
*Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;*
*Абый белән бергәләшеп, кара җирне*
*Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.*
*Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,*
*Билгесездер — кая ташлар бу тәкъдирем;*
*Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,*
*Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.*



**<u>Кызыклы шәкерт</u>**

**Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!
— Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.
Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.
— Ах, җүләр маэмай! тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул:
Картаеп каткач буыннар — эш белү уңгайсыз ул!**



**КҮБӘЛӘГЕМ**

*Татар халык җыры*





**Күбәләк гөлләргә кунса,**
**Гөлләр тибрәнә микән?**
**Ул да мине сагынганда,**
**Күбәләгем, түгәрәгем,**
**Асыл кошым, сандугачым,**
**Җырлап җибәрә микән?**

**Күбәләккәй гөлгә кунган,**
**Гөлдә булгач оясы;**
**Минем күңелем сиңа тарта,**
**Күбәләгем, түгәрәгем,**
**Асыл кошым, сандугачым,**
**Син бит күңелем кояшы.**





**Тау астында, тал астында**
**Салкын чишмә түгәрәк;**
**Очып барып кайтыр идем,**
**Күбәләгем, түгәрәгем,**
**Асыл кошым, сандугачым,**
**Әгәр булсам күбәләк.**

**<u>Чияле</u>**

**Сандугачның балалары**
**Талга кунганнар икән.**
**Кызларыгыз тыршып укый –**
**Бигрәк уңганнар икән.**

**Эх, чия, чия, чия,**
**Чия, чияләгәндә,**
**Чия алсу, матур була**
**Яңгыр сибәләгәндә.**
**Эх,чия,чия,чия,**
**Чияле тау итәге,**
**Чияле тау итәгендә**
**Бер ял итеп кит әле.**

**Йөгреп төштем,сулар эчтем ,**
**Су баса кибеккәне.**
**Китап мактый,халык хаклый,**
**Тигез гомер иткәнне.**

**Йөгреп төштем,сулар эчтем**
**Яр буенда,елгада.**
**Эштә алдынгы булганнар,**
**Дан казана дөньяда.**



**<u>Бала белән күбәләк</u>**

**Габдулла Тукай**

**Бала:**
**Әйт әле, Күбәләк,**
**Сөйләшик бергәләп:**
**Бу кадәр куп очып**
**Армыйсың син ничек?**
**Ничек соң тормышың?**
**Ничек көн күрмешең?**
**Сөйләп бирче тезеп,**
**Табаламсың ризык?**

**Күбәләк:**
**Мин торам кырларда,**
**Болында, урманда;**
**Уйныймын, очамын**
**Якты көн булганда.**
**Иркәли һәм сөя**
**Кояшның яктысы;**
**Аш буладыр миңа**
**Чәчәкләр хуш исе.**
**Тик гомрем бик кыска:**
**Бары бер көн генә,—**
**Бул яхшы, рәнҗетмә**
**Һәм тимә син миңа!**



**Татар биюләре.**
**Әпипә.**

**Бас, кызым, Әпипә,**
**Син басмасаң, мин басам,**
**Синең баскан эзләреңә**
**Мин дә китереп басам.**

**Бас, кызым, Әпипә,**
**Син басмасаң, мин басам,**
**Әпипәнең калачларын**
**Ашап калам ичмасам.**

**Бас, кызым, Әпипә,**
**Идәннәре селкенсен;**
**Идәннәре селкенсен дә,**
**Кияү күңеле җилкенсен.**

**Бас, кызым, Әпипә,**
**Сындыр идән тактасын,**
**Сындырсаң идән тактасын,**
**Кияү түләр акчасын.**







**Каз канаты**

**Каз канаты кат-кат була,**
**Ир канаты ат була;**
**Чит җирләрдә бик күп йөрсәң,**
**Сөйгән ярың ят була.**

**Каз канаты каурый-каурый,**
**Хатлар язарга ярый.**
**Уйнамагач та көлмәгәч,**
**Бу дөнья нигә ярый.**

**Каз канаты ап-ак була,**
**Ир канаты ат була;**
**Чит илләрдә йөргән чакта**
**Бик сагынган чак була.**



**ҖЫР ”ЯЗ КИЛӘ”**

**Кояш көлеп карый безгә,**
**Күзләр чагыла,**
**Елгалардан бозлар ага**
**Диңгез ягына.**

**Яз, яз, яз  җитә,**
**Тәрәзәне ачтылар.**
**Тып – тып – тып итә**
**Эре – эре тамчылар.**

**Агачка кунып, чыпчыклар**
**Чыелдашалар,**
**Яшькелт – кара сыерчыклар**
**Әй җырлашалар.**

**Тиздән шаулап яфрак ярыр**
**Озын ак каен,**
**Ал чәчәкләр алып килер**
**Безгә май ае.**



**Әминә Бикчәнтәева**
**Дәү әнием.**

**Әниемнең әнисе**
**Әбием була минем.**
**Әби генә түгел әле,**
**Ул минем дәү әнием.**
**Ак ефәктәй чәчләрен**
**Ул тарап куя үреп,**
**Чисталыкка өйрәнәм**
**Мин дә, аңардан күреп.**
**Тәмле ашлар пешерә,**
**Матур гөлләр үстерә,**
**Өебезнең нуры ул,**
**Барыбыздан олы ул.**
**Кызыклы әкиятләр**
**Сөйли кичләрен безгә,**
**Бәбкәм, -- диеп, иркәләп**
**Эндәшә үзе безгә.**
**Җылы оек, бияләй**
**Бәйли безгә, күз җиткәч.**
**Мин дә аңа бүләкләр**
**Алырмын үсеп җиткәч.**





**Гөлшат Зәйнашева**
**Кояш гомере.**

**Бер кыз бала җыр чыгарган,**
**Багышлап әнисенә.**
**Икәү бергә җырлыйк диеп,**
**Өйрәткән энесенә:**

**Кояш, кояш мәңге балкый,**
**Мәңге нур сибә.**
**Кояш гомере телим**
**Мин, әнием, сиңа!**

**Җырны чишмәләр ишеткән,**
**Кошлар отып алганнар.**
**Сандугачлар һәм тургайлар**
**Матур көйгә салганнар:**

**Кушыл син дә, җырлыйк бергә,**
**Яңа матур җыр тусын.**
**Җирдә әниләр кояштай**
**Озын гомерле булсын!**

Мин Чапаев абыемны
Кинодан күреп беләм.
Аңа охшарга тырышып
Кара папаха киям.

Папаха әтиемнеке
Шуңа зур ул башыма.
Күпме күтәреп куйсам да,
Һаман төшә кашыма.

Исем китми аңа минем.
Мин Чапай дип шатланам.
Кылыч алып, йөгреп барам,
Күк кашкама атланам.

Папаха бар йөри торган,
Атым гына юк минем.
Чапай кебек батыр булсам,
Ансын да бирер илем.






**1.Бар минем дускаем,**
**Иң якын сердәшем.**
**Һәр җирдә, һәр эштә**
**Киңәшчем, иптәшем.**

**2.Өйрәтә ул миңа**
**Бар фәнне, телләрне.**
**Юк аның белмәгән**
**Сәңгате, Һөнәре.**

**3.Иң якын дускаем,**
**Киңәшчем ул китап.**
**Җырлыймын мин аны**
**Олылап һәм мактап.**

Чеп, чеп, чебиләрем,
Чеп, чеп, чеп, чеп, чебиләрем,
Йомры, йомшак йомгакларым,
Минем нәни елакларым.
1.Әйдә яшел чирәмдә сез
Гәпләшегез тирәмдә сез.

Ай, минем чебиләрем, / 4 /
Минем сөйгән нәниләрем.
Чеп, чеп, чебиләрем,
Чеп, чеп, чеп, чеп, чебиләрем,
Йомры, йомшак йомгакларым,
Минем нәни елакларым.
2. Ни телисез мин бирәмен,--
Су бирәмен, җим бирәмен.

3. Бер көн килер – сез үсәрсез,
Йомырка бүләк итәрсез.



**1. Шәл бәйләдем,/ 4 /**
**Шәлем түгәрәк түгел лә,/2**

**2. Очып барып күрер идем**
**Җаным күбәләк түгел лә/2**

**3. Сулар ага арыктан ла/2/**
**Кызлар карый ярыктан/2/**

**4. Сикереп төшеп биер идем/2/**
**Ояламын халыктан ла/2/.**

